ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

02.03.2023 ел №78

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә ТР Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге СоветыНЫҢ 2016 елның 12 маендагы 26 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең реестрларын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 7 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 20 пунктында «Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесенә» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгына (Рәисенә) һәм Татарстан Республикасы Администрациясе җитәкчесенә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/"Турай авыл җирлеге" бүлегендә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык, хокук тәртибе һәм Кеше хокуклары буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Турай авыл җирлеге
Советы рәисе урынбасары Р.Р.Шәймөхәммәтов